**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетын төзү турында**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын әзерләүдә һәм уздыруда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында **карар бирәм:**

1. 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетын төзергә.

2. 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 20 декабрь
№ ПУ-865

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «20» декабрендәге
ПУ-865 номерлы Указына
1 нче кушымта

**2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турындагы нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты (алга таба – Республика оештыру комитеты) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең 2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын (алга таба – чемпионат) оештыру һәм уздыруда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

2. Республика оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм аның башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Республика оештыру комитетының төп бурычлары

3. Республика оештыру комитетының төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Казан шәһәрен чемпионатны уздыруга әзерләү чараларының ведомствоара планын формалаштыру буенча тәкъдимнәр эшләү (алга таба – Чараларның ведомствоара планы);

Казан шәһәрен чемпионатны уздыруга әзерләү белән бәйле планнарны, программаларны һәм аерым чараларны гамәлгә ашыруның барышына анализ, Чараларның ведомствоара планын үтәүгә һәм аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән акчаның максатчан файдалануына контрольне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары), Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм

җәмәгать берләшмәләренең Республика оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарларны тормышка ашыру процессында үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр эшләү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

Чараларның ведомствоара планын үтәү белән бәйле бурычларны хәл иткәндә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

4. Республика оештыру комитеты үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

Республика оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләреннән Республика комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

законнар нигезендә WorldSkills International халыкара оешмасыннан Үзара аңлашу турындагы меморандум, чемпионатка әзерлек буенча нигезләмәләр, регламентлар, тәкъдимнәр чемпионатны әзерләү һәм уздыруга кагылышлы башка документлар соратып алырга;

Республика оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзергә;

үз утырышларына билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасының җитәкчеләрен һәм башка вәкилләрен чакырырга;

чемпионатны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

## III. Республика оештыру комитеты составы

5. Республика оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан формалаштырыла һәм раслана.

6. Республика оештыру комитеты составына аның рәисе, рәисенең урынбасарлары, секретаре һәм Республика оештыру комитеты эшендә җәмәгать башлангычларында катнашучы башка әгъзалары керә.

7. Республика оештыру комитеты рәисе итеп Татарстан Республикасы Премьер-министры куела.

8. Республика оештыру комитеты рәисе:

Республика оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итә, Республика оештыру комитеты утырышларында мәсьәләләрне карап тикшерүнең исемлеген, срокларын һәм тәртибен билгели;

Республика оештыру комитеты рәисе урынбасарларына һәм әгъзаларына вәкаләтләрне (бурычларны) бүлеп бирә;

Республика оештыру комитеты эшчәнлеге планы нигезендә утырышларның көн тәртибен, аларны уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

үзе булмаган вакытка Республика оештыру комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп үзенең урынбасарларының берсен билгели;

утырыш беркетмәләренә һәм Республика оештыру комитетының башка документларына кул куя.

9. Республика оештыру комитеты секретаре:

Республика оештыру комитеты утырышларында катнаша;

Республика оештыру комитеты әгъзаларына биш көннән дә соңга калмыйча, утырышны уздыру датасын, вакытын һәм урынын хәбәр итә, утырышның көн тәртибен һәм аның материалларын җибәрә;

Республика оештыру комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

10. Республика оештыру комитеты әгъзалары:

Республика оештыру комитеты утырышында шәхсән катнаша;

Республика оештыру комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куя;

Республика оештыру комитеты карап тикшерә торган мәсьәләләр буенча материаллар белән таныша;

Республика оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү, аларның үтәлешенә контрольлек итү буенча кирәкле чараларны башкара.

## IV. Республика оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

11. Республика оештыру комитеты утырышлары ким дигәндә ике айга бер тапкыр уздырыла. Республика оештыру комитеты рәисе тарафыннан утырышлар уздыру графигы раслана һәм бу мәгълүмат Республика оештыру комитеты әгъзаларына җиткерелә.

12. Кирәк булган очракта, рәис Республика оештыру комитетының чираттан тыш утырышын билгели. Бу очракта секретарь Республика оештыру комитеты әгъзаларына Республика оештыру комитетының чираттан тыш утырышы буласы көнгә кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр бирә.

13. Республика оештыру комитеты утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча материаллары секретарьга утырыш билгеләнгән датадан 15 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Карап тикшерелергә тиешле материалларга нигезләнеп секретарь Республика оештыру комитеты утырышы көн тәртибен төзи һәм аны утырыш уздырыласы көнгә кадәр 12 эш көненнән дә соңга калмыйча Республика оештыру комитеты рәисенә раслауга бирә.

14. Республика оештыру комитеты рәисе утырышның көн тәртибен утырыш уздырыласы көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча раслый. Утырышның көн тәртибе расланганнан соң Республика оештыру комитетына карап тикшерү өчен мәсьәләләр кую бары тик рәис карары белән генә

мөмкин була. Бу очракта Республика оештыру комитеты рәисе Республика оештыру комитеты секретарена утырышның көн тәртибенә өстәмә кертү һәм бу турыда Республика оештыру комитеты әгъзаларына хәбәр итү хакында күрсәтмә бирә.

15. Республика оештыру комитеты утырышларын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

16. Республика оештыру комитеты әгъзалары утырышларда шәхсән катнаша. Республика оештыру комитеты утырышта катнашмаган очракта, карап тикшерелә торган мәсьәләләр турында фикерен ул язма рәвештә тапшырырга хаклы.

17. Республика оештыру комитеты утырышлары, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була. Әгәр утырышта катнашучы әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше Республика оештыру комитеты карарын хуплап тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала. Республика оештыру комитеты утырышларында көн тәртибе мәсьәләләрен карап тикшерү һәм тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә торган карарлар кабул ителә. Республика оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә утырышта рәислек итүче кул куя.

18. Республика оештыру комитеты кабул итә торган карарлар нигезләнеп эш итү һәм көндәлек эшчәнлекләрен башкару өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренә, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасына, кызыксынган башка затларга җиткерелә.

19. Республика оештыру комитеты карарларына нигезләнеп Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары проектлары әзерләнергә мөмкин.

## V. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

20. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник, документлар, мәгълүмат һәм транспорт белән тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле структур бүлекчәләре башкара.

21. Республика оештыру комитеты WorldSkills International халыкара оешмасы белән үзара хезмәттәшлек итә һәм бу оешмага кирәкле барлык мәгълүматны, шул исәптән Татарстан Республикасының чемпионатны уздыруга әзерлеге мәсьәләләре буенча, Республика оештыру комитеты кабул иткән карарлар һәм Ведомствоара чаралар планын үтәү барышы турында мәгълүматларны тапшыра.

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «20» декабрендәге
ПУ-865 номерлы Указына
2 нче кушымта

**2019 елда Казан шәһәрендә «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Республика оештыру комитеты рәисе |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Эмиль Фидаил улы | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры киңәшчесе, «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры, Республика оештыру комитеты секретаре (килешү буенча) |
| Габделганиев Фәрит Солтан улы | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Агиев Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарә рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Афанасьев Михаил Павлович | «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Афанасьев Андрей Игоревич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча Чик буе идарәсе «Идел буе» чик буе контроль отрядының «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пункты башлыгы (килешү буенча) |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бариев Марат Мансур улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча) |
| Вахитов Радик Рафикъ улы | Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы |
| Габдерәшитов Булат Рәшит улы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе башлыгы |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гайнетдинов Айдар Рафаил улы | Татарстан Республикасының «Созвездие-Йолдызлык» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры, Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы рәисе (килешү буенча) |
| Гаязов Зөфәр Фәдип улы | Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясе идарәсе рәисе, «Татинтер Ресторантс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гобәйдуллин<br>Әгъзам Самат улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча) |
| Гомәров<br>Рөстәм Фәрит улы | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Җәләлова<br>Анфиса Григорьевна | Казан педагогика көллияте директоры, «Татарстан Республикасының урта һөнәри белем бирү учреждениеләре директорлар советы» коммерциячел булмаган партнерлыгы рәисе (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Зарипова<br>Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Иванов<br>Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Кәримов<br>Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Когогин<br>Сергей Анатольевич | «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Лаврентьев<br>Александр Петрович | «Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |
| Леонов<br>Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Маврина<br>Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мәүликов<br>Альберт Вәзил улы | Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Мәганов<br>Наил Өлфәт улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнегалиев<br>Роберт Хәмит улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, «Казан Экспо» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Мифтахов<br>Рамил Зөфәр улы | Татарстан Республикасының туристлык агентлыклары ассоциациясе президенты, «Персона Грата» хосусый туристлык агентлыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллин<br>Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |
| Патяшина<br>Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе житәкчесе (килешү буенча) |
| Пустовгаров<br>Юрий Леонидович | «Казан вертолет заводы» гавами акционер җәмгыяте идарәче директоры (килешү буенча) |
| Рәхимов<br>Илнур Сөләйман улы | Татарстан Республикасының «Универсиада авылы» дәүләт автоном учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Садыйков<br>Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |

| | |
|---|---|
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Терентьев<br>Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Уразов<br>Роберт Наил улы | «Яшь профессионаллар (Ворлдскиллс Россия)» һөнәри берләшмәләр һәм эшче кадрларны үстерү агентлыгы генераль директоры (килешү буенча) |
| Фазлыева<br>Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| Фәйзуллин<br>Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры |
| Фәрдиев<br>Илшат Шәех улы | «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Фәттахов<br>Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Хәбибуллин<br>Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хамаев<br>Азат Кыям улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Хәмитов<br>Динар Газиз улы | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Хохорин<br>Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Шаһивәлиев<br>Тимур Наил улы | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шәйхетдинов<br>Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Шиһабетдинов<br>Альберт Кашаф улы | «ТАИФ» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Якубов<br>Йосыф Җиһанша улы | Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе ректоры (килешү буенча) |

___